ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ СОВХОЗНО-ГАЛАКТИОНОВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 48

Чистай муниципаль районы
Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 47/1 номерлы карары, Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 11 номерлы карары белән, Совхозно-Галактионовский муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Галактион совхозы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2019 елда 100 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы:

- Александровка авылындагы зиратны тотып алырга;
- Фиков- Колок авылы эчендәге юлларны төзекләндерүгә (щебень сатып алырга һәм китертергә)

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге
башлыгы В.Л.Донеев